**КАРАР Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы «Яңа Элмәле авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Яңа Элмәле авылында гражданнар җыены**

**27.11.2020 г.** **Яңа Элмәле авылы** **№ 1**

**Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы «Яңа Элмәле авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Яңа Элмәле торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында 2020 елның 27 ноябре**

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Яңа Элмәле авыл җирлеге Уставының 12.1 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Яңа Элмәле авыл җирлеге башлыгының 17.11.2020 ел, № 9 карары белән расланган Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Яңа Элмәле авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турындагы нигезләмәләр, әлеге хисап комиссиясе нигезендә 2020 елның 27 ноябрендә узган тавыш бирү нәтиҗәләре турында беркетмә төзелде, аның нигезендә:

Халык җыенында катнашучылар исемлегенә тавыш бирү тәмамланган вакытта җыенда катнашучылар исемлегенә халык җыенында катнашучы 498 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны-310, бу-торак пункт территориясендә гражданнар җыенында катнашучылар исемлегенә кертелгән гражданнарның 62,25% ын тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

халык җыенында катнашкан 310 кеше «За» позициясе өчен тавыш бирде, Бу-тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучыларның 100 % ын тәшкил итә; «каршы» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучы 0 кеше тавыш бирде, бу- 0 %.

Бәян ителгәннәр нигезендә хәл иттеләр:

1. 2020 елның 27 ноябрендә Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының «Яңа Элмәле авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Яңа Элмәле торак пунктында гражданнар җыенын 2020 елның 27 ноябрендә уздырылган дип таныргa, гражданнар җыены нәтиҗәләре-дөрес.

2. "Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Яңа Элмәле авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны Яңа Элмәле буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2021 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алдагы эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрүгә килешәсезме?:

-Үзәк, Ленин, Яңа Элмәле авыллары буенча гамәлдәге юлларга вак таш салу;

- Көнчыгыш, Суворов, Яңа Элмәле урамнары буенча юл-урам челтәрен ремонтлау».

3. 2021 елда Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Яңа Элмәле авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны Яңа Элмәле буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзсалым кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:

-Үзәк, Ленин, Яңа Элмәле авыллары буенча гамәлдәге юлларга вак таш салу;

- Көнчыгыш, Суворов, Яңа Элмәле урамнары буенча юл-урам челтәрен ремонтлау.

4. Халык җыены нәтиҗәләрен «Туган як» газетасында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының Яңа Элмәле авыл җирлеге башлыгына Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Яңа Элмәле авыл җирлеге башлыгы,
рәислек итүче халык җыенында: Р.Н. Дружков